КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 сентябрь г.Казань № 840

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 март, 133 нче; 2016 ел, 8 май, 286 нчы; 2016 ел, 21 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 6 июнь, 345 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 894 нче; 2017 ел, 30 декабрь, 1133 нче; 2019 ел, 16 февраль, 111 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 774 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 923 нче; 2020 ел, 14 апрель, 285 нче; 2020 ел, 30 июнь, 548 нче; 2020 ел, 16 июль, 600 нче; 2020 ел, 3 сентябрь, 779 нчы; 2021 ел, 15 февраль, 82 нче; 2021 ел, 5 май, 309 нчы; 2021 ел, 8 июнь, 442 нче; 2021 ел, 16 август, 731 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 22 ноябрь, 1109 нчы; 2022 ел, 3 февраль, 81 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1047 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1159 нчы; 2022 ел, 20 декабрь, 1375 нче; 2023 ел, 24 февраль, 182 нче; 2023 ел, 25 апрель, 524 нче; 2023 ел, 2 май, 555 нче; 2023 ел, 27 июль, 899 нчы; 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче; 2023 ел, 19 октябрь,

1323 нче; 2023 ел, 11 декабрь, 1599 нчы; 2023 ел, 19 декабрь, 1645 нче; 2024 ел, 31 гыйнвар, 50 нче; 2024 ел, 13 февраль, 76 нчы, 2024 ел, 25 май, 365 нче, 2024 ел, 2 август, 614 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.6 – 3.3.8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.6. Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йорттан күчерү, чыгу һәм вакытлыча чыгу Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Психик тайпылышлар белән интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан күчерелү, чыгу һәм вакытлыча чыгу тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2024 елның 3 апрелендәге 176н номерлы боерыгы белән расланган Психик тайпылышлар белән интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан күчерелү, чыгу һәм вакытлыча чыгу тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3.7. Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йорттан социаль хезмәтләр алучылар янына социаль хезмәт күрсәтүнең стационар оешмаларында булган гражданнарның хокукларын яклауны һәм мондый гражданнарга психиатрия ярдәме күрсәткәндә хокукларның һәм законлы мәнфәгатьләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы законлы вәкилләре, адвокатлары, нотариуслар, иҗтимагый һәм (яисә) башка оешмалар вәкилләре, руханилар, туганнары һәм башка затлар, шулай ук «Гражданнарның психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 46 статьясындагы беренче - өченче өлешләрендә күрсәтелгән органнар һәм оешмалар вәкилләре бару психик тайпылышлардан интегүче затлар өчен билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасындагы зат янына керүне оештыруга карата Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Психик тайпылышлардан интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында булган затка баруны оештыруның гомуми таләпләрен раслау турында» 2024 елның 6 маендагы 247н номерлы боерыгы белән расланган гомуми таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3.8. Чыкканда (күченгәндә) гражданга һәм (яисә) аның законлы вәкиленә исемлек буенча граждан документларының, шул исәптән медицина документлары, төп нөсхәләрен һәм күчермәләрен, шулай ук психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йортта сакланган гражданның шәхси әйберләрен тапшыралар.

Вакытлыча чыкканда гражданга яисә аның законлы вәкиленә йә вакытлычы чыгучы балигъ яшьтәге гражданны кабул итүче психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат-йорт тарафыннан исемлек буенча граждан документларының, шул исәптән медицина документлары, төп нөсхәләрен һәм күчермәләре, шулай ук гражданның шәхси әйберләре тапшырыла.»;

4.3.8 һәм 4.3.9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.8. Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортлардан, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортлардан күчерү, чыгу һәм вакытлыча чыгу Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Психик тайпылышлар белән интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан күчерелү, чыгу һәм вакытлыча чыгу тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2024 елның 3 апрелендәге 176н номерлы боерыгы белән расланган Психик тайпылышлар белән интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан күчерелү, чыгу һәм вакытлыча чыгу тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.3.9. Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йорттан, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат-йортлардан социаль хезмәтләр алучылар янына социаль хезмәт күрсәтүнең стационар оешмаларында булган гражданнарның хокукларын яклауны һәм мондый гражданнарга психиатрия ярдәме күрсәткәндә хокукларның һәм законлы мәнфәгатьләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы законлы вәкилләре, адвокатлары, нотариуслар, иҗтимагый һәм (яисә) башка оешмалар вәкилләре, руханилар, туганнары һәм башка затлар, шулай ук «Гражданнарның психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 46 статьясындагы беренче - өченче өлешләрендә күрсәтелгән органнар һәм оешмалар вәкилләре бару психик тайпылышлардан интегүче затлар өчен билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтү стационар оешмасындагы зат янына керүне оештыруга карата Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Психик тайпылышлардан интегүче затлар өчен билгеләнгән стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмасында булган затка баруны оештыруның гомуми таләпләрен раслау турында» 2024 елның 6 маендагы 247н номерлы боерыгы белән расланган гомуми таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Чыкканда (күченгәндә) гражданга һәм (яисә) аның законлы вәкиленә исемлек буенча граждан документларының, шул исәптән медицина документлары, төп нөсхәләрен һәм күчермәләрен, шулай ук гражданның шәхси әйберләрен тапшыралар.

Вакытлыча чыкканда гражданга яисә аның законлы вәкиленә йә вакытлычы чыгучы балигъ булмаган гражданны кабул итүче исемлек буенча граждан документларының, шул исәптән медицина документлары, төп нөсхәләрен һәм күчермәләре, шулай ук гражданның шәхси әйберләре тапшырыла.».

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин